КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 декабрь г.Казань № 1177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 26 июнь, 531 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

01.15.01.1 дәүләт идарәсенең дүртенче дәрәҗә коды буенча "ЦО" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР ИМ»;

файдаланылган кыскартулар исемлегенең уундүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1263 нче; 2020 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы; 2020 ел, 6 март, 180 нче; 2020 ел, 31 август, 759 нчы, 2020 ел, 22 сентябрь, 853 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «148» саннарын «242» саннарына алмаштырырга, «3 358,171 мең сум» сүзләрен «4 945,931 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның икенче абзацында «8 данә» сүзләрен «тугыз данә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта “биш” сүзен “алты" сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «2007 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм аның структурасы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 22 декабрь, 1177 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасының икътисадый үсеше, инвестиция һәм инновация эшчәнлеге белән идарә итү буенча дәүләт сәясәтен эшләү, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын формалаштыру, Россия Федерациясе дәүләт программаларын, федераль максатчан программаларны формалаштыруда катнашу функцияләрен гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт җайга салуын тормышка ашыручы, шулай ук дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасының, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының социаль-икътисадый хәлен, халыкның тормыш дәрәҗәсен, хуҗалык субъектларының тотрыклы эшләвен мониторинглауны, идарәчел карарлар кабул итү өчен мәгълүмат базасын формалаштыруны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора.

Министрлык түбәндәге өлкәдә вәкаләтле орган булып тора:

Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлекне һәм интеллектуаль милек өлкәсен үстерү;

конкуренция үсешенә ярдәм итү;

Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру һәм территориаль үсеш;

эшкуарлыкны үстерү.

1.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә оештыру-хокукый рәвешенә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.3. Министрлык федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.5. Министрлык юридик зат булып тора, банк учреждениеләрендә мөстәкыйль баланс, исәп-хисап счеты һәм башка счетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән матбугат һәм үзенең символикасы бар.

1.6. Министрлыкның урнашкан урыны: 420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55 нче йорт.

## 2. Министрлыкның бурычлары

2.1. Министрлыкның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1.1. Индикатив идарә методын кулланып, Татарстан Республикасы икътисадын җайга салу буенча дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру.

2.1.2. Республика территориясендә җитештерү көчләрен оптималь һәм нәтиҗәле урнаштыруны тәэмин итү максатларында республика территориаль үсешенең бердәм схемасы нигезендә төбәк үсешенең дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру.

2.1.3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән, шулай ук җирле үзидарә органнары белән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда үзара хезмәттәшлеген оештыруда катнашу.

2.1.4. Бердәм дәүләт инновацион сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру.

2.1.5. Бердәм дәүләт инвестиция сәясәте өстенлекләрен формалаштыру һәм дәүләт ярдәмен күрсәтү.

2.1.6. Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү һәм халыкның үзмәшгульлеген үстерү, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый сәясәтен гамәлгә ашыруда эшмәкәрлекнең ролен күтәрү, икътисадта конкурент мохит булдыру, эшкуарлыкка инвестицияләр җәлеп итү, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым кертемнәрен арттыру максатларында эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.

2.1.7. Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыру һәм үстерү һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү.

2.1.8. Татарстан Республикасында эшкуарлык торышына һәм инвестицияләр өчен шартларга мониторинг ясау һәм комплекслы анализ ясау.

2.1.9. Дәүләт конкурентлык сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру.

2.1.10. Интеллектуаль милек булдыру, аны саклауны тәэмин итү, интеллектуаль милеккә хокукларны саклау һәм яклау өчен шартлар формалаштыру.

2.1.11. Илкүләм проектлар составында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм Татарстан Республикасында төбәк проектларын гамәлгә ашыруны координацияләү.

2.1.12. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый мониторингы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.

2.1.13. Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләрнең) социаль-икътисадый хәлен мониторинглауны алып баруны оештыру.

2.1.14. Татарстан Республикасы территориясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен булдыру һәм үстерү буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.

## 3. Министрлык функцияләре

3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

социаль-икътисадый программалаштыру (01.01*):

озак вакытлы этапка исәпләнгән социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.01*);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.02*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09*);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11*);

интеллектуаль милек өлкәсен үстерү белән идарә итү (01.11.01*);

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1*);

Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү (01.19*);

икътисадны мобилизацион әзерләү белән идарә итү (02.04*);

социаль өлкә белән идарә итү (04*).

3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән массакүләм мәгълүмат чаралары аша җәмгыятьтә толерант мөнәсәбәтләрне саклау өлкәсендә этномәдәни проектларны (мәдәният өлкәсендәге проектлар), милли иҗтимагый берләшмәләрне гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (01.24*);

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү (01.12*);

белем бирү белән идарә итү (04.05*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07*);

яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.26*);

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча».

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлеге һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү(01.03*);

энергияне һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне җайга салу (03.05*);

эчке товар базарын аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне билгеләнгән тәртиптә җайга салу (этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүдән һәм аларны әйләнештә йөртүдән тыш) (03.05.02*);

социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү (03.07*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

«Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.23*);

авыл хуҗалыгы белән идарә итү (03.02*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

территориаль планлаштыру (01.05.01*);

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (04.01*);

архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.25*);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт комплексы белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт белән идарә итү (01.13*);

инвалидларның, ветераннарның һәм пенсионерларның иҗтимагый берләшмәләре, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү, социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.27*);

социаль яклау белән идарә итү (04.06*);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү,

мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән цифрлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09*);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләт-шәхси партнерлык һәм шәхси инвестицияләр өлкәсендә инвестицион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү , инвестицион проектларны гамәлгә ашыруны комплекслы тәэмин итү функцияләрен тормышка ашырганда(01.10*);

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан түбәндәге функцияләрне башкарганда:

Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау (саклау, файдалану һәм популярлаштыру) өлкәсендә иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.28*);

Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру (04.03.03*);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10*).

## 4. Министрлыкның вәкаләтләре

4.1. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

4.1.1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

4.1.2. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасын проектка кертү өчен тәкъдимнәр формалаштыра.

4.1.3. Татарстан Республикасының икътисадый хәленә анализ ясый һәм аның нигезендә дәүләт структур, инновацион сәясәтне, Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге белән дәүләт идарәсен гамәлгә ашыру принципларын, ысулларын һәм рәвешләрен, шулай ук индикатив идарә итү системасы нигезендә Татарстан Республикасы икътисадын дәүләти җайга салуны билгели.

4.1.4. Татарстан Республикасының уртача һәм озак сроклы чорларга социаль-икътисадый үсеш фаразларын эшләүне гамәлгә ашыра.

4.1.5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белән берлектә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында еллык хисап төзи.

4.1.6. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләүдә катнаша, территорияләрне билгеләү, үстерү һәм файдалану мәсьәләләре буенча килештерелгән карарлар кабул итү өчен җитештерү көчләрен һәм аларны гамәлгә ашыру планнарын урнаштыруны тәэмин итә.

4.1.7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлеген түбәндәгеләр буенча координацияли:

Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү көчләрен урнаштыру һәм үстерү;

Татарстан Республикасының җитештерү көчләрен үстерү һәм урнаштыру схемасын төзү һәм урнаштыру өчен икътисадый-картографик материаллар эшләү өчен мәгълүмат базасын булдыру һәм үстерү;

Татарстан Республикасының дәүләт өлеше булган эре, икътисадый һәм социаль әһәмиятле (система барлыкка китерүче) оешмаларның, предприятиеләрнең һәм Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы бюджет барлыкка китерүче предприятиеләрнең финанс-икътисадый торышын мониторинглау һәм анализлау.

4.1.8. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген координацияли.

4.1.9. Түбәндәгеләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып тора:

Татарстан Республикасында алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрын алып бару буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасында алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлек башкару турында килешүне төзү, үзгәртү һәм өзү.

4.1.10. Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

иҗтимагый инфраструктура объектларын, иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен, тәэмин ителешнең түбән дәрәҗәсе, югары дәрәҗәдәге тузуның өстенлекле үсеше дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертү өчен сайлау;

капиталь кертемнәргә җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге предметына инвестиция проектларын тикшерү нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү;

территориаль планлаштыру документларына бәяләмәләр әзерләү.

4.1.11. Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза үткәрә.

4.1.12. Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетның төп параметрлары нигезендә дәүләт заказчылары буенча дәүләт капитал салулары күләмен бүлү турындагы тәкъдимнәрне әзерләүне оештыра һәм координацияли.

4.1.13. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең һәм чыгымнарының аерым статьяларын икътисадый нигезләүне тәэмин итә.

4.1.14. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының

оештыру структурасын формалаштыру һәм санын оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша.

4.1.15. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, алар буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә функциональ анализ ясый һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенә функциональ анализ буенча методик база әзерләүне һәм камилләштерүне гамәлгә ашыра.

4.1.16. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең сыйфатын методологик тәэмин итүне һәм мониторинглауны гамәлгә ашыра.

4.1.17. «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасын алып бара, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) турында белешмәләр урнаштыру өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасын алып бару буенча вәкаләтле орган белән мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

4.1.18. Законнар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү мониторингын гамәлгә ашыра.

4.1.19. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актларны эшләүдә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтә.

4.1.20. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне җайга салучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын камилләштерүне, шул исәптән электрон рәвештә күрсәтелә торган, дәүләт ярдәме чараларын, күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын килештерүне дә кертеп, күрсәтүне җайга сала.

4.1.21. Күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр саны турында 1-ГМУ, 2-ГМУ федераль статистик күзәтү формалары буенча квартал саен статистик мәгълүмат җыеюны гамәлгә ашыра.

4.1.22. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ реформа уздыру һәм үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.1.23. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү буенча аудит уздыруда катнаша.

4.1.24. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә һәм функцияләр башкарганда дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының ведомствоара һәм ара үзара хезмәттәшлеген оештыруны методологик яктан тәэмин итә.

4.1.25. Татарстан Республикасының комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүне мониторинглау өчен кирәкле федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары күрсәткечләрен раслау өчен тәкъдимнәр әзерли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

4.1.26. Алып бара:

үз компетенциясе нигезендә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм башка гавами-хокукый характердагы актлар реестрын;

Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Хөкүмәте яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исеменнән үз компетенциясе нигезендә төзелгән гавами-хокукый характердагы шартнамәләрнең, килешүләрнең һәм башка актларның җыелма реестрын;

Татарстан Республикасының координация (киңәшмә) органнары реестрын;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларының бердәм реестрын;

социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның - ярдәм алучыларның республика реестрын;

федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның республика реестрын.

4.1.27. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы формалаштыра.

4.1.28. Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеген, Татарстан Республикасында контроль-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм камилләштерү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә.

4.1.29. Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма органнары исемлеге алып бара.

4.1.30. Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында һәм тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан әзерләнә торган мондый контрольнең нәтиҗәлелеге турында докладлар җыю;

төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру һәм мондый контрольнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында җыелма докладны, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында һәм мондый контрольнең нәтиҗәлелеге турында җыелма докладны әзерләү, күрсәтелгән җыелма докладларны Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына тапшыру.

4.1.31. Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын килештерүне һәм Россия Федерациясе дәүләт программаларын, федераль максатчан программаларны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыра.

Бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш финанс чыганаклары исәбеннән финанслана торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген төзи.

Россия Федерациясе дәүләт программаларының, федераль максатчан программаларның, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының үтәлешенә мониторинг үткәрә.

4.1.32. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре мәсьәләләре буенча хөкүмәт карарларын әзерләүдә катнаша.

4.1.33. Муниципаль берәмлекләр дәрәҗәсендә стратегик планлаштыру документларын эшләүдә җирле үзидарә органнарына методик ярдәм күрсәтә.

4.1.34. Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен ирешелгән күрсәткечләр турында Татарстан Республикасы Президенты докладының проектын формалаштыра.

4.1.35. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен эшли

4.1.36. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планын формалаштыруны гамәлгә ашыра

4.1.37. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының планлаштырылган күрсәткечләренә ирешү турында килешүләр әзерләү өчен җаваплы булып тора.

4.1.38. Хисап елында Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә мониторинг ясау нәтиҗәләре һәм аларның өч елга планлаштырыла торган күрсәткечләре турында Татарстан Республикасының җыелма доклады проектын әзерләү эшен җайга сала.

4.1.39. Татарстан Республикасының моношәһәрләре икътисадын диверсификацияләү, аларны модернизацияләү, Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләрнең) социаль-икътисадый хәлен бәяләү мәсьәләләре буенча эшне координацияли.

4.1.40. Дәүләт ярдәмен алу өчен тапшырыла торган инвестиция проектларына экспертиза ясый.

Дәүләт ярдәме алган Татарстан Республикасы инвестиция проектлары буенча мәгълүматлар банкы алып бара.

Инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары бирүне күздә тоткан инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында шартнамәләр төзи.

Татарстан Республикасында инвестиция салым кредиты бирү турында карар кабул итә.

4.1.41. «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 7 өлешендә каралган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү

өлкәсендәге вәкаләтләрне Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра:

капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү төзү турында кушымтада бирелгән документлар һәм материаллар белән гаризаны карый;

Татарстан Республикасы исеменнән капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләргә һәм аларга өстәмә килешүләргә имза сала;

капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзүгә бәйле документларны, шул исәптән «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 12 өлешендә каралган документларны, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең элегрәк төзелгән шартнамәне тану турында үтенечнамәсен, мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бурычларының капитал салуларын яклау һәм бүләкләү турындагы килешүгә кертү хакында үтенечнамәсен карый;

капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында һәм шулардан килеп чыга торган бәхәсләрне җайга салу турында килешүләрне үзгәртү һәм туктату турында карарлар кабул итә;

инвестиция проектын гамәлгә ашыру этаплары мониторингын уздыра, аңа карата капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү төзелгән;

капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү кысаларында инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешманың чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар бирү шартларын үтәүне бәяли.

4.1.42. Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлек күрсәткечләрен мониторинглауны һәм анализлауны гамәлгә ашыра.

4.1.43. Татарстан Республикасы инновацион инфраструктурасы субъектлары эшчәнлегенә мониторинг һәм анализ ясый.

4.1.44. Татарстан Республикасында граждан билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре нәтиҗәләрен дәүләт исәбенә алу һәм саклау координацияләнә.

4.1.45. Фәнни-техник өлкәдә кече предприятиеләрне үстерүгә ярдәм итү фонды конкурсларында катнашу буенча эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтә.

4.1.46. Татарстан Республикасында акыл мөлкәте объектларын хокукый саклауны һәм алардан файдалануны анализлау гамәлгә ашырыла.

4.1.47. Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлек һәм интеллектуаль милек өлкәсен үстерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле органы сыйфатында федераль башкарма хакимият органнары һәм инновацион үсеш институтлары белән хезмәттәшлек итә.

4.1.48. Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлек йомгаклары турында дәүләт доклады әзерли.

4.1.49. Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган инновацион һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән алга таба тормышка ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновацион проектларга экспертиза үткәрүне оештыруны тәэмин итә.

4.1.50. Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясенең инновация сәясәте буенча мәгълүмати-аналитик һәм оештыру-техник эшчәнлеген тәэмин итә.

4.1.51. Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумы нигезләмәләрен эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен җаваплылык үзәге булып тора.

4.1.52. Татарстан Республикасы электрон товар-мәгълүмат системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге эшчәнлеген www.tattis.ru сайтында тәэмин итә.

